| | |
|---|---|
| МИНИСТЕРСТВО<br>СЕЛЬСКОГО ХОЗЯЙСТВА<br>И ПРОДОВОЛЬСТВИЯ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ<br>ҺӘМ АЗЫК-ТӨЛЕК<br>МИНИСТРЛЫГЫ |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

17.03.2015 г.Казань № 47/2-пр.

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы чыгара торган норматив хокукый актларга һәм ул әзерли торган норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза ясау турында

“Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында” 2009 елның 17 июлендәге 172-ФЗ номерлы Федераль законны, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Аерым норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза ясау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында” 2009 елның 24 декабрендәге 883 номерлы карарын гамәлгә ашыру максатларында, шулай ук коррупциячел факторларны ачыклау һәм алга таба аларны бетерү өчен

б о е р ы к б и р ә м:

1. Кушымта итеп бирелгән Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы чыгара торган норматив хокукый актларга һәм ул әзерли торган норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза ясау тәртибен расларга.

2. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны министрның беренче урынбасары Н.Л. Титовка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
урынбасары – министр М.Г. Әхмәтов

Татарстан Республикасы
Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының
2015 елның 17 мартындагы
47/2-пр номерлы боерыгы
белән расланды

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы чыгара торган норматив хокукый актларга һәм ул әзерләп бирә торган норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза ясау тәртибе

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Тәртип "Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында" 2009 елның 17 июлендәге 172-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында" 2010 елның 26 февралендәге 96 номерлы карары белән расланган Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза ясау методикасы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Аерым норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза ясау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында" 2009 елның 24 декабрендәге 883 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы (алга таба – Министрлык) чыгара торган норматив хокукый актларга һәм ул әзерләп бирә торган норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза ясау һәм коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәләрен исәпкә алу кагыйдәләрен билгели.

2. Коррупциягә каршы экспертиза әзерләнә торган норматив хокукый актлар проектларына (алга таба – норматив хокукый актлар проектлары) хокукый экспертиза ясаганда һәм Министрлыкның кабул ителгән норматив хокукый актларына (алга таба – норматив хокукый актлар) мониторинг үткәргәндә ясала.

3. Коррупциягә каршы экспертизаның максаты норматив хокукый актларда һәм норматив хокукый актлар проектларында коррупциячел факторларның булуын ачыклаудан һәм алга таба аларны бетерүдән гыйбарәт.

4. Коррупциягә каршы экспертиза үз көчләрен югалткан яисә гамәлдән алынган норматив хокукый актларга ясалмый.

## II. Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза ясау тәртибе

5. Коррупциягә каршы экспертиза Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 26 февралендәге 96 номерлы карары белән расланган Норматив хокукый

актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза ясау методикасына (алга таба – Методика) нигезләнеп ясала.

6. Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры (алга таба – Министр) Министрлыкта коррупциягә каршы экспертиза ясау өчен җаваплы вазыйфаи затны (алга таба – вазыйфаи зат) билгеләп куя. Күрсәтелгән зат шулай ук Министрлыкта Коррупциягә каршы экспертизага кергән норматив хокукый актларны һәм норматив хокукый актлар проектларын исәпкә алу журналын (алга таба – Журнал) (1 нче кушымта) алып бару өчен җаваплы була.

7. Норматив хокукый акт чыгарган яки норматив хокукый акт проектын эшләгән структур бүлекчә (алга таба – акт әзерләп бирүче) аны коррупциягә каршы экспертиза ясау өчен вазыйфаи затка юллый, бу гамәл Журналда экспертизага керү көнендә теркәлә.

8. Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза ясау срогы Журналда теркәлгән көненнән ун көннән дә артык була алмый.

9. Коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәләре буенча вазыйфаи зат бәяләмә әзерли һәм имзалый.

Коррупциячел факторларның булуы турында бәяләмәдә (2 нче кушымта) коррупциягә каршы экспертиза ясаганда ачыкланган коррупциячел факторлар күрсәтелә һәм аларны бетерү ысуллары тәкъдим ителә.

Норматив хокукый актларда һәм норматив хокукый актлар проектларында коррупциячел факторлар булмаса, коррупциячел факторларның булмавы турында бәяләмә (3 нче кушымта) рәсмиләштерелә һәм акт әзерләп бирүчегә җибәрелә.

10. Экспертизага җибәрелгән норматив хокукый акт проектында коррупциячел факторлар булмаса, акт әзерләп бирүче, коррупциячел факторларның булмавы турында бәяләмә алганнан соң, мәнфәгатьле структур бүлекчәләр җитәкчеләренең визалары куелган норматив хокукый акт проектын имзалау өчен Министрга кертә.

11. Норматив хокукый актта коррупциячел факторлар ачыкланса, вазыйфаи зат коррупциячел факторларның булуы турында бәяләмәне акт әзерләп бирүчегә коррупциячел факторларның булуы ачыкланган вакыттан алып эш көне дәвамында юллый.

Акт әзерләп бирүче, бәяләмә алганнан соң, Министр белән килештереп, аңа үзгәрешләр кертү зарур булу турында яки аның үз көчен югалтуын тану турында карар кабул итә һәм ачыкланган коррупциячел факторларны бетерү максатыннан үзгәрешләр кертү турында норматив хокукый акт проектын яисә норматив хокукый актның үз көчен югалтуын тану турында проект әзерли һәм коррупциягә каршы экспертиза ясау өчен вазыйфаи затка җибәрә.

12. Экспертизага җабәрелгән норматив хокукый акт проектында коррупциячел факторларның булуы ачыкланса, акч чыгаручы, коррупциячел факторларның булуы турында бәяләмә алганнан соң, өч көн эчендә барлык җитешсезлекләрне бетерергә һәм эшләп бетерелгән норматив акт проектын кабат коррупциягә каршы экспертиза ясау өчен җибәрергә тиеш.

13. Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына кабат коррупциягә каршы экспертиза ясау срогы өч көннән артык түгел.

14. Коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәләре Журналда күрсәтелә.

15. Министр норматив хокукый актны, норматив хокукый акт проектын Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты раслаган тәртиптә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына коррупциягә каршы экспертизага җибәрергә хокуклы.

## III. Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза ясау тәртибе

16. Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза объектларын Министрлыкның рәсми басылып чыккан норматив хокукый актлары һәм Министрлык әзерли торган норматив хокукый актларның "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең рәсми Порталына урнаштырылган проектлары тәшкил итә.

17. Дәүләт сере булып торган белешмәләрне яисә конфиденциаль белешмәләрне үз эченә алган норматив хокукый актларга, норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза ясалмый.

18. Норматив хокукый акт проектына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза ясау өчен акт әзерләп бирүче аны Министр боерыгы белән норматив хокукый актлар проектларын урнаштыру өчен җаваплы дип билгеләнгән затка (алга таба – Җаваплы зат) юридик бүлеккә аларны карау өчен юллаган көнгә туры килә торган эш көне эчендә җибәрә.

19. Җаваплы зат норматив хокукый акт проектын акт әзерләп бирүчедән алган көнгә туры килә торган эш көне эчендә аны "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Министрлыкның рәсми сайтына урнаштыра.

20. Норматив хокукый актлар проектларын аларга коррупциягә каршы бәйсез экспертиза ясау өчен урнаштырганда Җаваплы зат экспертиза бәяләмәләрен юллау өчен адресны (шулай ук электрон почта адресын), шулай ук коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча бәяләмәләрне кабул итә башлау һәм төгәлләү даталарын күрсәтә.

21. Норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза ясау срогы аларны "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырган көннән алып биш эш көнен тәшкил итә.

22. Норматив хокукый актка, норматив хокукый акт проектына ясалган коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча Министрлыкка килгән бәяләмә (алга таба – бәяләмә) карау өчен акт әзерләп бирүчегә җибәрелә.

23. Бәяләмә тәкъдимнәр рәвешендә язылган була һәм Министрлык тарафыннан мәҗбүри рәвештә каралырга тиеш. Норматив хокукый актны, норматив хокукый акт проектын әзерләп бирүче коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча килгән бәяләмәне (алга таба – бәяләмә) карый һәм нигезләнгән җавапны коррупциягә каршы бәйсез экспертиза ясаган юридик яки физик затка бәяләмә алган көннән алып 15 көн эчендә җибәрә, моңа ачыкланган коррупциячел факторларны бетерү ысулы турында бәяләмәдә тәкъдимнәр булмаган очраклар керми.

24. Норматив хокукый актка, норматив хокукый акт проектына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза ясаганда ачыкланган коррупциячел факторлар акт әзерләп бирүче тарафыннан ун көн эчендә бетерелә.

25. Акт әзерләп бирүче, коррупциягә каршы бәйсез экспертиза бәяләмәсендә бәян ителгән күрсәтмәләрне бетергәннән соң һәм тәкъдимнәрне исәпкә алганнан соң, норматив хокукый акт проектын, коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча килгән бәяләмәләрне аңа теркәп, кабат карау өчен вазыйфаи затка кертә. Кабат карау өч көн эчендә башкарыла.

26. Әгәр коррупциячел факторлар норматив хокукый актта ачыкланган булса, акт әзерләп бирүче Министрлыкта бәяләмә теркәлгән көннән алып өч көн эчендә норматив хокукый актка үзгәрешләр кертү яисә аның үз көчен югалтуын тану буенча чаралар күрә.

27. Коррупциягә каршы бәйсез экспертизаның норматив хокукый актларда һәм норматив хокукый актлар проектларында коррупциячел факторларның булуын исбатлый торган нәтиҗәләре белән Министрлык килешмәгән очракта, Министрлык күрсәтелгән норматив хокукый актларны, норматив хокукый актлар проектларын, коррупциягә каршы бәйсез экспертиза бәяләмәсен һәм үзенең килешмәве нигезләнгән аңлатманы теркәп, законнарда билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына коррупциягә каршы экспертизага юллый.

28. Акт әзерләп бирүче коррупциягә каршы, шул исәптән бәйсез экспертизаның аның тарафыннан әзерләнгән Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы тәртибендә Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертелә торган федераль закон проектларында, Татарстан Республикасы законнары проектларында, Татарстан Республикасы Президенты указлары проектларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары проектларында коррупциячел факторларның булуын исбатлый торган нәтиҗәләре белән килешмәгән очракта, ул күрсәтелгән норматив хокукый актлар проектларын Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каравына кертә.

Министрлык чыгара торган норматив хокукый актларга һәм ул әзерләп бирә торган норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза ясау тәртибенә
1 нче кушымта

## Коррупциягә каршы экспертизага кергән норматив хокукый актларны һәм норматив хокукый актлар проектларын исәпкә алу

Журналы

| № | Экспертизага акт (акт проекты) кергән көне | Актны (акт проектын) әзерләп биргән структур бүлекчәнең исеме | Актның (акт проектының) исеме | Экспертиза ясау срогы | Коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәсе | Бәяләмәне структур бүлекчә белгече алган көн һәм аның имзасы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| | | | | | | |

Министрлык чыгара торган норматив
хокукый актларга һәм ул әзерләп бирә
торган норматив хокукый актлар
проектларына коррупциягә каршы
экспертиза ясау тәртибенә
2 нче кушымта

**Коррупциячел факторларның булуы турында бәяләмә**

____________________________________________________________
(норматив хокукый актның яки норматив хокукый акт проектының исеме)

“Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында” 2009 елның 17 июлендәге 172-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында” 2010 елның 26 февралендәге 96 номерлы карары белән расланган Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза ясау методикасы нигезендә Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы коррупциячел факторларны ачыклау һәм алга таба аларны бетерү максатларында
____________________________________________________________
(норматив хокукый актның яки норматив хокукый акт проектының исеме)
коррупциягә каршы экспертиза ясады.

Тәкъдим ителгән ______________________________________________
(норматив хокукый актның яки норматив хокукый акт проектының исеме)

түбәндәге коррупциячел факторларның булуы ачыкланды:
____________________________________________________________
(коррупциячел факторларның төрләре күрсәтелә)
____________________________________________________________

Ачыкланган коррупциячел факторларны бетерү максатларында түбәндәгеләр тәкъдим ителә:
____________________________________________________________
(коррупциячел факторларны бетерү ысулы күрсәтелә)

_____________________ __________ ____________________________
(вазыйфа исеме) (имза) (инициаллар, фамилия) (дата)

Министрлык чыгара торган норматив
хокукый актларга һәм ул әзерләп бирә
торган норматив хокукый актлар
проектларына коррупциягә каршы
экспертиза ясау тәртибенә
3 нче кушымта

**Коррупциячел факторларның булмавы турында бәяләмә**

______________________________________________________________
(норматив хокукый актның яки норматив хокукый акт проектының исеме)

“Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында” 2009 елның 17 июлендәге 172-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында” 2010 елның 26 февралендәге 96 номерлы карары белән расланган Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза ясау методикасы нигезендә Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы коррупциячел факторларны ачыклау һәм алга таба аларны бетерү максатларында

______________________________________________________________
(норматив хокукый актның яки норматив хокукый акт проектының исеме)
коррупциягә каршы экспертиза ясады.

Тәкъдим ителгән ______________________________________________
(норматив хокукый актның яки норматив хокукый акт проектының исеме)

коррупциячел факторлар юк.

______________________ __________ ______________________________
(вазыйфа исеме) (имза) (инициаллар, фамилия) (дата)